ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
№ 22

Постановление
28 июль 2025 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында"15.07.2019 елгы 10 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында.

"Дәүләти муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 27.07.2010 елгы 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен үтәү йөзеннән Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 15 июлендәге 10 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Карарның 1.5 пунктның 10 абзацы, 2 нче кушымталарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"планлаштыру структурасының элементы-зона (массив), район (шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы, яр буе), коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен урнаштыру территорияләре;"

1.2.Карарның 1.5 пунктның 11 абзацы 2 нче кушымталарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"урам-юл челтәренең элементы - урам, проспект, тыкрык, юл, мәйдан, бульвар, тупик, съезд, шоссе, аллея һәм башкалар;";

1.3. Карарның 1 нче кушымтаның 2.4 п. түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

"Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы:

AnyScanner

- гариза язмача бирелгән очракта, гариза кергән көннән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча;

- электрон документ рәвешендә гариза биргән очракта-гариза кергән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча.

Муниципаль хезмәтне алдан кисәтү (проактив) режимда күрсәткән очракта-дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәннән соң 3 эш көне.»

2. Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районының авыл җирлекләре бүлегендәге рәсми сайтында һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче: Б.Ф.Хасанов